# КАРАР

## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче Яңа Мокшино авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 һәм 15 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә" 05.11.2019 ел № 105 карарга таянып Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Мокшино авылында 2025 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре беркетмәсе төзелде.: Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юлындагы чокырларны ремонтлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту җайланмасы (светодиодлы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 122 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 74 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Риза»- 74 катнашучы тавыш бирде;

- «Каршы» - 0 катнашучы тавыш бирде;
- «Тыелдым»-0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Мокшино торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләре – дөрес дип таныргa.

2. Мәсьәлә буенча КАРАР кабул дип таныргa Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юлындагы чокырларны ремонтлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту җайланмасы (светодиодлы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы Н.В.Айдова

СОВЕТ СТАРОУЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ